Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№31 (45)

8 ноябрь 2012 ел

## • Универ хәлләре

**РЕКТОР ИЛШАТ ГАФУРОВ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ ДЕЛЕГАЦИЯСЕНЕҢ ЛОЗАН ФЕДЕРАЛЬ ПОЛИТЕХНИК МӘКТӘБЕНӘ (ШВЕЙЦАРИЯ) ВИЗИТЛАРЫ ДӘВАМ ИТӘ.** 1 ноябрь көнне университет вәкилләре «Майндмейз» компаниясе һәм кәүсә күзәнәкләренең динамика лабораториясе белән таныштылар. 2 ноябрьдә Казан федераль университеты белән Лозан федераль политехник мәктәбе арасында мәгариф һәм фән өлкәсенә караган хезмәттәшлеккә кул куелды. Аңа кадәр инде делегация визуальләштерү һәм компьютерлы модельләштерү лабораториясе; архитектура, гражданлык һәм экология инженериясе факультетының IT-технологияләр бүлеге; житештерүчәнлек өчен микроинженеринг лабораториясе һәм механик металлургия лабораторияләрендә булып кайтты.

• • • •

Шушы көннәр аралыгында Яр Чаллыдагы IT-парк конференцзалында республика студентлар үзидарәсе җитәкчеләре катнашында **VII ТР СТУДЕНТЛАР КОНГРЕССЫНА ӘЗЕРЛӘНҮ УҢАЕННАН «ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ» ҮТТЕ.** Чара беренчә секциягә бүленеп уздырылды: студентлар үзидарәсе; спорт, сәламәт яшәү рәвеше, куркынычсызлык нигезләре; социаль юнәлеш; фән һәм мәгариф; мәдәният һәм иҗат. КФУның Яр Чаллы филиалы студентлары әлеге «түгәрәк өстәл»дә актив катнашып, үзләре өчен актуаль булган, шул исәптән республикабызда студентлар үзидарәсе концепциясенең үсеше кебек сорауларга җавап эзләде.

• • • •

1 ноябрь көнне университетка Грециянең беренче вице-губернаторы – **КОСТАС КАРАПАНАЕТИДИС ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘГЕ ҮЗӘК МАКЕДОНИЯ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ КИЛДЕ.** Визит программасы Казан университетының Тарих музее белән танышудан башланып китте. Килгән кунакларны тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов, ТР фән һәм мәгариф министрлыгы урынбасары Андрей Поминов һәм «ТР студентлар лигасы»төбәк яшьләренең иҗтимагый оешмасы Президенты Тимур Сөләйманов озатып йөрделәр. Соңрак Греция вәкилләре республика студентлар үзидарәсе җитәкчеләре, студентлар өчен проектлар җитәкчеләре белән очрашып, үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап алды.

• • • •

1-2 ноябрь көннәрендә КФУның Яр Чаллы филиалында **«ЯШЬ ПОЛИГЛОТ» ЛИНГВИСТИК МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫ АЛДЫНДА ИШЕКЛӘРЕН АЧЫП ҖИБӘРДЕ.** Чара ел саен мәктәп укучыларының көзге каникул вакытында оештырыла. Быел үткәрелгән дәресләрнең башкалардан аерылып торган бер үзенчәлеге бар: испан һәм кытай телләре буенча ике мастер-классны Миларгос Исабель де Мария Гарсия Передес һәм Ли Чженьвень тел йөртүчеләре үткәрде. Европа һәм Көнчыгыш телләренең лингвокультурологик үзенчәлекләреннән тыш, югары сыйныф укучылары инглиз теленнән БДИ язу күнекмәләрен булдырды, имтихан барышында туарга мөмкин булган сорауларны карап үтте.

• • • •

9 ноябрьдә Казан федераль университетының Exploration Operating Company Limited компаниясе белән хезмәттәшлеге уңаеннан «Хәзерге заман икътисад теориясенең яңа юнәлеше буларак системалы икътисад» дип аталган студентлар, магистрлар, аспирантлар һәм укытучылар өчен **АЧЫК ЛЕКЦИЯ ОЕШТЫРУ ПЛАНЛАШТЫРЫЛА.** Чара Россиянең әйдәп баручы икътисадчысы, Россия Фәннәр Академиясенең В.С. Немчинов исемендәге премия лауреаты, Үзәк икътисади-математика институтының директор урынбасары, профессор Георгий Борис улы Клейнерның Казанга килү уңаеннан оештырыла.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*







Диана Поварова фотосы

# «Лобачевский укулары - 2012»

Динара **ЗИННӘТОВА**,
хәбәрче

2–6 ноябрь көннәрендә университетта «Лобачевский укулары – 2012» дип аталган XI Бөтенроссия яшьләр мәктәп-конференциясе үтте. Ул танылган галимнәрнең берсе - математик Николай Лобачевскийның тууына 220 ел тулуга багышланды.

Казан федераль университеты актлар залы Россиянең төрле төбәкләреннән килгән яшь укытучылар, фәнни хезмәткәрләр, аспирант-магистрантлар һәм өлкән курс студентларын җыйды. Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институты директоры Владимир Чугунов быел олуг галим Николай Иванович Лобачевский тууына 220 ел тулуы белән котлады һәм университет үсешенә керткән зур өлеше белән таныштырды. Н.И.Лобачевский кырык ел дәвамында биредә укыткан, шул исәптән 19 ел буе ректор булып эшләгән. Активлыгы һәм җитәкчелек осталыгы университетны Россиянең иң алдынгы уку йортлары санына кертергә ярдәм иткән. Россия хокукының тарихы белгече, танылган җәмәгать эшлеклесе Н.П.Загоскин Н.И.Лобачевскийны «Казан университетының бөек төзүчесе» дип атаган.

Пленар утырышлар белән беррәттән, конференция кунаклары өчен университет һәм Казан буйлап экскурсияләр дә оештырылды.

Конференция барышында алдынгы Россия галимнәре һәм чарада катнашучылар докладларын укыды. Оештыручы комитет тарафыннан сайлап алынган материаллар «Н.И.Лобачевский исемендәге Математика үзәге хезмәтләре»нең чираттагы томында басылачак.

Яшьләрдә фәнгә карата кызыксыну уяту, аларның бу өлкәдәге сәләтләрен ачу җәмгыятебезнең, илебезнең киләчәктәге үсеше өчен зур әһәмияткә ия. «Лобачевский укулары» конференциясе студентларга, фән белән мавыгучы яшь укытучыларга үз көчләрен сынап карарга, компетентлы кешеләрдән үз хезмәтләренә объектив бәя алырга мөмкинлек бирде.

## • Белем баскычлары

# Мин үскәч галим булам

Динә **МӨХТӘСИПОВА**,
хәбәрче

Бу уку елында «Балалар университетында» өченче мәртәбә узган лекция астрономиягә багышланды.

400дән артык кечкенә студентыбыз һәм әти-әниләрен Галәм серләре белән Физика институты профессоры, физика-математика фәннәре докторы Наил Сәхибуллин таныштырды. Лектор сөзләренчә, балалар бик белемле, әзерлекле. «Нинә ел укыту тәҗрибәсе булуга карамастан, мондый аудитория белән беренче тапкыр очраштым, бик каушадым. Шундый авыр материалны балаларга җиткерә алмам дип курыктым. Юкка борчылганмын икән. Нәни укучыларым сорауларга тулы җавап кайтарды, алай гына да түгел үзләре дә сораулар биреп утырды. Бу аларның фәнгә тартылуы турында сөйли. Михайло Ломоносов сүзләре белән әйтсәк, Россия әле үзенең Невтоннарын тудырачак», – диде профессор.

«Балалар университеты» кечкенәләрне генә түгел, студентларны да үзеннән «җибәрми». Әйтик, кайбер активист һәм волонтерлар университетны тәмамлагач та, биредә эшләүләрен дәвам итә.

**Ахыры 2нче биттә.**



■ *Антоний Свердруп.* Диана Поварова фотосы

● Халыкара багланышлар

# Төрекмәнстан-Татарстан күпере

**Альберт БОРҺАНОВ,**
Тарих институты профессоры



Быел Төрекмәнстанның бәйсезлек алуына – 21 ел, Татарстан конституциясен кабул итүгә 20 ел тулды. Шушы уңайдан Татарстанның Милләтләр дуслыгы йортының яңа бинасында «Төрекмәнстан – Татарстан: тарих, кайбер нәтиҗәләр һәм хезмәттәшлек перспективалары» исемле түгәрәк өстәл узды.

Чара ТР Милләтләр дуслыгы йорты, ТР төрекмәннәренең милли-мәдәни автономиясе, Төрекмәннәрнең дөньякүләм милләтара гуманитар ассоциациясе һәм Казан федераль университеты тарафыннан уздырылды.

Түгәрәк өстәлдә катнашучылар арасында шактый гына урынны КФУ галимнәре алып торды: Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Р.Сафиуллин, Филология һәм сәнгать институты профессоры Х.Ю.Миңнегулов, Тарих институты профессоры А.А.Борһанов, геология институты доценты С.О.Зорина һ.б. Чарада Төрекмәнстан һәм Татарстанның мәдәният, фән, мәгариф өлкәсендә багланышлар; татар-төрекмән мөнәсәбәтләренең тарихи үсеше, татар-төрекмән мөнәсәбәтләренең киләчәге кебек сорауларга җавап эзләнде, татар һәм төрекмән халыклары тарихына бәйле төрле фото һәм видеоматериаллар күрсәтелде, бу өлкәгә кагылышлы соңгы тарихи ачышлар турында докладлар укылды.

«Түгәрәк өстәл»дә катнашучыларның игътибарын иң җәлеп иткән әйбер: Төрекмәнстанның Койтендаг өлкәсенең Лебап велаятендә булган экспедиция нәтиҗәсендә ясалган видеофильм һәм видеопрезентация булды. Быелның җәендә Казан федераль университеты галимнәре АКШ, Канада, Бөекбритания, Франция, Италия, Финляндия, Россия һәм Төрекмәнстандагы хезмәттәшләре белән Койтендаг тауларында (Төрекмәнстанның көньяк көнчыгышы) бик зур тикшеренү эшләре алып барганнар иде. Белгечләр плато динозаврлар, карстлы мәгарәләр, археология һәм мәдәният һәйкәлләрен, төбәкнең бай табигатен тикшерү белән мәшгуль булдылар. Башкарылган эшләр нәтиҗәсендә Койтендагны тикшереп өйрәнүгә багышланган Халыкара фәнни коммисия оештырылды.

Экспедициядән кайтуга, КФУ ректоры, профессор Илшат Гафуровка ЮНЕСКО эшләре буенча Төрекмәнстанның Милли комиссиясе җаваплы сәркатибе һәм Төрекмәнстан Фәннәр Академиясе җитәкчелеге исеменнән рәхмәт хаты килде. Анда Татарстан галимнәренең югары профессиональ дәрәҗәләре турында берничә мәртәбә кабатлана. Димәк, белгечләребезне чит җирләрдә дә беләләр, алар белән горурланалар. Безгә бу биеклекне төшермичә, алга таба да шул юнәлештә эшләргә кирәк.



● Искә алу



# Ил агасы булган шәхес

**Рифат СӘЛАХ**

*(Марат Садыйковның тууына сиксән ел)*

«Үлгәннән соң макталу – терек булу, исән вакытта макталу – үлү вә онытылу», – дигән галимебез Ризаэтдин Фәхретдин. Чынлап та үлгәннән соң макталу бик сирәкләргә генә насыйп. 2 ноябрь көнне шундый шәхесләрнең берсе Казан университетының Тарих музеенда профессор, философия фәннәре докторы Марат Садыйковның 80 еллыгы үтте.

Иң беренче игътибарымны кешенең күп булуы, Тарих музееның күрше бүлмәләреннән урындыклар алып чыкканнары җәлеп итте. Бу бинада үткән бер генә мәҗлестә дә халыкның бу кадәр җыелган юк иде. Студентлар, аспирантлар, галимнәр – барысы да Садыйковны искә алырга килгән. Бу – шәхеснең никадәр зур булуын ачык күрсәтә торган дәлил.

Фәлсәфә факультеты деканы Михаил Щелкунов мәҗлесне ачып җибәргәндә: «Бу – фәлсәфә факультеты өчен генә түгел, бөтен университетыбыз өчен дә зур вакыйга!» – диде. Профессор исән вакытында туган көннәрен буш кына үткәрергә яратмаган, шул хөрмәткә уздырылган мәҗлесләр дә фәнни әңгәмәләргә әверелә торган булган.

Марат Садыйков философия факультетын булдыруда зур өлеш керткән шәхес кенә түгел. Аның бүгенге җәмгыятьне ничек дөрес итеп кору хакында зур хезмәтләре бар. Ул совет чорында ук үз фикерен актив белдергән. Коммунистлар хакимияттә булган заманның тарихыбызда калдырган уңай якларына да игътибарны юнәлдергән. Ул һәр чорның җәмгыятебез үсешенә уңай тәэсирен эзләгән. Бүгенге көннәргә: «Хәзер безнең ил халкында ике процесс бара: берәүләр – үз белгечлекләре турында да онытып, кая эш бар, шунда ялланып эшләүчеләр; икенчеләр исә байлык артыннан куа, аны арттырырга тырыша», – дип бәя биргән.

Фәлсәфә факультеты деканы урынбасары Татьяна Шатунова галимнең бик тыйнак кеше булганын искә алды, кыскача гына биографиясен сөйләде. Зур экранда аның яшьлек фотоларын карадык. Сурәтләрнең берсендә Марат Садыйковның Татьяна Михайловнаның битеннән үпкәне дә килеп чыкты. Бу Татьяна ханымның докторлык диссертациясен яклау кичәсе булган икән.

Мәҗлестә катнашучылар арасында аның биографиясендә партком секретаре вазифаларын үтәве турында еш кына онытып җибәрүләренә борчылучылар күп. Заманында төзүче отрядлары оештырып, Казан университеты хезмәткәрләренә йөз фатирлы йорт салуны оештырып та, шунда эшләп тә йөрүчеләрнең берсе булган. Шушы гамәле белән ул безгә граждannар җәмгыятенең чын үрнәген теориядә генә түгел, ә гамәлдә дә күрсәтте, ди хезмәттәшләре.

Марат Садыйков укулары чын мәгънәсендә аның шәхесен, хезмәтләрен бүгенге студентларга да җиткерде.

● Сәяхәттән кайткач

# Курганда күргәннәр

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Филология һәм сәнгать институты студентларының Курган өлкәсе Шадрин һәм Шатыртау районнарында үткәрелгән диалектологик практика нәтиҗәләренә багышланган конференциядә үземне Курган якларына барып кайткандай хис иттем...

Студентларның гыйлемен эш тәҗрибәсе белән ныгытып бару – ул югары уку йортында гадәти күренеш. Ә филологлар өчен, миңа калса, иң кызыгы, иң яратып үтә торганы диалектологик практика. Бу яктан КФУ да укучыларга менә дигән мөмкинлекләр бар: алар төрле төбәкләргә чыгып, халыкның теле, яшәеше белән таныша алалар. Быел профессор Фәрит Йосыпов җитәкчелегендә мондый сәяхәткә эләгүчеләргә кызыгып, соклanып карадым. Мөгаен, Курган өлкәсенең кайбер районнарында тел үзенчәлекләрен тикшерү бәхете татар филологиясе бүлегенең иң тырыш студентларына гына эләккәндер! Югыйсә, анда һәркем барырга теләр иде.

Диалектларны өйрәнеп утыру, сүз җыю кирәк тә түгел, ни өчен инде ул дип уйлаучылар нык ялгышалар. Татар филологиясе бүлеге мөдире Флера Сәйфулина: «Татар теленең байлыгын, үзенчәлекләрен барлау – ул исәп-хисапсыз байлык, чөнки һәр төбәктә татарлар бар. Алар сүз белән яши. Ә бу байлыкны җыеп туплау – безнең бурыч. Яшьлектә төшенеп бетмәсәң дә, олыгайгач моның кирәклеген чын-чынлап аңлыйсың», – диде. Дөрестән дә, башка милләттәшләрнең, әбибабаларыбызның тел үзенчәлекләрен тикшерү зур хезмәт кенә түгел, киләчәк буын өчен алтын бәһасендә йөрердәй мәгълүмат.

Конференция дәвамында студентлар эзләнү-күзәтүләре турында чыгыш ясады. Эчкен татарларының яшәү рәвеше, исем кушу, күмү, дини йолалар, туй үткәрүләре турында чыгышлар кызыклы булды. Әле берәрегезнең кыз белән егетнең туй алдыннан көрәшкәнен күргәнегез йә булмаса ишеткәнегез бар идеме? Бу киләчәктә гаиләдә кем баш булачагын, кемнең сүзе үтәчәген хәл итү максатыннан оештырыла икән. Туган-тумачалар шунда гаиләнең киләчәк тормышын күзаллап, бер-берсенә ни булса да гаеп итмәскә дигән максат куялар. Кызларның егетне сорап килүе турында, гомумән, белмисездер! Кыз урлап китү – монда гадәти күренеш, бер урланган кызның кире кайтмаячагы һәркемгә мәгълүм. Экспедиция вакытында кызлар бик теләп шундый үзенчәлекләрне өйрәнгән. Шуларны әдәби-музыкаль күренеш итеп сәхнәләштерү чараны тагын да бизәп җибәрде. Ул гына да түгел, ахырдан кызлар килгән кунакларны Курган өлкәсеннән язып алган рецепт буенча пешерелгән шәңгәләр белән сыйлады.

Әйе, һәр якның үз сүзләре, традицияләре бар. Бары тик бу юнәлештә эшләүчеләр күбрәк булсын иде. Курган өлкәсе үзенчәлекләрен безгә җиткерүче студентларга алдагы эзләнүләрендә уңышлар теләп калабыз!



• Галимнәребез

Ибраһим Хәлфин – университетыбыз тарихында әһәмиятле урын алып торучы, татар теле белеменә зур өлеш керткән шәхес. Әтисе һәм бабасы эшен дәвам итеп, үз тормышын татар телен үстерүгә, аның ролен күтәрүгә багышлый.

# Ибраһим Хәлфин - беренче татар адъюнкт-профессоры

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

Мәскәү университетын тәмамлау белән, Хәлфин 1800 елдан, әтисе һәм бабасы эшен дәвам иттереп, Казанның беренче ирләр гимназиясендә татар теле укытучысы булып эшли башлый. Гимназиядә Азия типографиясе оешкач, аның цензоры да булып китә. Типографиянең беренче 8 ел эшчәнлеге дәверендә 24 төрле мөселман китабы дөнья күрә. Беренче өч ел эчендә генә татар һәм гарәп телләрендә 31 мең данә китап бастырыла. Ә иң уңышлы һәм рекордлы ел дип, 1806 нчы ел санала, бу елда 27 мең данә дөнья күрә (Коръән китаплары, әлифбалар, грамматикалар). Күп кенә чит ил әгъзалары да, бу китапларны күргәндә, Россиядә мөселман халкына нинди киңлекләр ачылганына таң кала торган булган. Бу вакытта аңа нибары 22 яшь кенә була. 1804 елда Казан император университеты ачылгач, ул бирегә татар телен укытучы-лектор булып килә.

Ибраһим Хәлфин университетта эшләгән беренче татар галиме. Ана теленнән тыш, биредә ул төрек һәм гарәп телләрен дә укыта, көнчыгышны өйрәнү өлкәсендә фәнни эзләнүләр алып бара. Ул укыткан фәннәрдән дәреслекләр җитми, шуңа күрә китапларны үзе тәрҗемә итә башлый, кирәкле хезмәтләр яза. 1809 елда Казанда аның урыс телендә язылган «Азбука и грамматика татарского языка с правилами арабского чтения...» дәреслеге басыла. Моннан тыш, галим, студент П.Юнаков белән берлектә, татар телендә кыскача Россия тарихы һәм географиясе, арифметика китапларын да чыгара.

Ибраһим Хәлфин татар халкын Россия һәм Европаның мәдәни казанышларына якынайтуга, татар әдәби телен формалаштыруга, аның дәрәҗәсен күтәрүгә зур өлеш кертә. Олуг галим милләттәшләрен төрле тантаналарга, театр тамашаларына чакыра, татарларны актив мәдәни тормышка тарта. Күп кенә мәгълүматларга караганда, Ибраһим Хәлфин бик шук, аралашучан, шаян, шуның белән беррәттән бик тырыш һәм җаваплы кеше була.

1812 елда галим Казан университетының Шәрык кафедрасында эшли башлый. 1823 елда ул, татарлардан беренче булып, «адъюнкт-профессор» (профессор ярдәмчесе) дәрәҗәсенә ия була. Беррәттән профессор вазыйфаларын да үти башлый. 1828 елда Ибраһим Хәлфинны тагын да югарырак урынга – университетның төрки телләр һәм әдәбиятлары кафедрасы җитәкчесе итеп билгелиләр.

И.Хәлфин фәнни әйләнешкә керткән мәгълүматлар, Австриянең Көнчыгышны өйрәнүче тарихчы галиме Йозеф Гаммер хезмәтләре аша, К.Маркс белән Ф.Энгельска да билгеле була. Казан галиме, иске төрки кабилә диалектларын өйрәнүче Әбрар Кәримуллин Ленинградта Пушкин йортында бик кызыклы фактка тап була. Ибраһим исеме Россия һәм Европа илләрендә генә түгел, ә Америкада да билгеле булган, 1861 елның 8 июлендә Америка табибы, галиме Отто Рериг, Казанга хат язып, И.Хәлфиннән Сиу-Сиу индеецлары теленең татар теле белән уртаклыгы мәсьәләсе буенча аңлатмалар бирүен үтенә. Үзенең дә татар телен бик күптәннән кызыксынып өйрәнүен искәртә.

• Әдәп-әхлак

# Үпкәләсәң әйдә, үпкәлә...

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Университта, дуслар арасында, башка җирләрдә еш кына үпкәчел кешеләр белән очрашырга туры килә. Һәм нигәдер аларны кызганып куям. Юктан борчылып, боегып йөриләр, ә күп очракта бу нерв авырулары белән дә катлауланып китәргә мөмкин. Хәтта шундый очраклар була: студент укытучыга үпкәли, имеш, ул дөрес билге куймаган, йә дөрес сүз әйтмәгән, йә шелтә белдергән. Әгәр дә холкыгыз еш үпкәләүгә корылган икән, тиз арада моннан чыгу юлларын эзләргә кирәк!

Еш кына юктан да үпкәләп, дуслар – дошманга, туганнар – читкә, күршеләр бөтенләй ят кешегә әйләнә. Очраклы гына әйтелгән сүзгә дә еллар буе үпкә хисе саклап йөртергә мөмкинбез. Уйлап караганыгыз бармы: кирәкме икән? Ачуланышмыйча гына хәл итсәк, яхшырак түгелме?

Үпкәләтергә теләсәләр, нәрсә эшләргә диярсез. Урынлы сорау. Үпкәгә үпкә белән җавап биргәнче, шундый түбәнлеккә төшмәү күпкә хәерлерәк булыр. Гадәттә үзара килешмәүләрнең сәбәбе бик тирәндә була, ә тирәнгә төшү өчен күп актарынырга кирәк.

Бернигә карамастан, барыбер үпкәләргә уйласагыз, алдан математик исәпләүләр ясагыз: алыгыз, бүлегез, тапкырлагыз һ.б. Әгәр дә сезне тулысынча гаепле булмаган килеш кыерсытсалар, күңелегездә уянган үпкә катыш нәфрәт хисеннән үзегезгә кагылмаган өлешен, башка кешегә эләгергә тиешлесен алып ташлагыз. Башыгызда шулай эчтән генә гап-гади математик операцияләр үткәреп, бушанып калыгыз. Ашка таш белән атудан мәгънә юк. Әгәр елмаю белән җавап кайтарсагыз бөтенесе сезнең файдага булачак.

Дөресен генә әйткәндә, чиктән тыш тиз үпкәләү, эндәшмичә йөрү – ул ахмаклык билгесе. Үз-үзен хөрмәт иткән кеше бу очракта акыллырак була белергә тиеш. Үпкәләмәскә!

Инглизләрдә яхшы гына бер кагыйдә бар: сезне аңлы рәвештә рәнҗетсәләр генә, үпкәләргә ярый. Ә инде гап-гади игътибарсызлык, хәтерсезлек (гадәттә мондый сыйфатлар өлкәнрәк буын кешеләрендә, йә булмаса арыган вакытларда очрый), вак-төяккә хәтерегез калырга тиеш түгел. Киресенчә, үзенә игътибар күрсәтегез, бу күпкә матуррак һәм күркәмрәк.

Үпкәләүче, үпкәләтүчеләр белән саграк булу иң хәерлеседер. Үпкәчел булу – бик интектерә торган сыйфат. Кешенең җаны эчтән тынычлык бирми, үз-үзенә урын таба алмый, күңелләре ката... Ә иң куркынычы: каты күңелләләр, башкага золым теләп үпкәләп йөрүчеләр дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле була алмаслар.

• Ана теле

# Испан мәктәбе юк, ә татар мәктәбе бармы?

**Рифат СӘЛАХ**



Күптән түгел Нельсон Вальдес дигән уенчыбызны югалттык. Казан «Рубин»ында бер елга якын һөҗүмче ролен башкарган егетнең китүен җанатарлар төрлечә кабул иткәндер... Хәзер ул Испаниянең «Валенсия» футбол клубында. Уен дәрәҗәсе дә югарырак, яңа клуб Ауропа чемпионнары лигасында да катнаша, ә Казан «Рубин»ы быел Ауропа лигасында гына. Китү сәбәбе (әллә сылтавымы?) генә безнең өчен сәер. Быел Нельсонның кызы укырга бара икән. Ә Казанда испан мәктәбе юк. Нишлисең, бала ана телендә белем алырга тиеш. Киләчәк турында уйлау һәркемнең изге бурычы! Мондый гамәленнән соң футболчыга хөрмәтем бермә-бер артты. Карьера, эштә зур уңышларга ирешү максатын читкә куеп, гаиләгә, үз милли йөзеңне, телеңне саклап калуга кемнәр генә шулкадәр игътибар бирә икән! Бу бигрәк тә яртылаш маңкортлашкан татар халкы җанатарлары алдында әйтелгән сүзләр безне дә уйландырырга тиеш. Дөресен генә әйткәндә, мин белгән татар спортчыларының бик сирәге генә милләтенә аерым әһәмият бирә.

Уйланып калдым да, балам булып, укырга барса, Казан шәһәреннән туган авылыма кайтып китәрмен, иншалла. Ни дисәң дә, Казан шәһәрендә татар мәктәбе юк! Дөрес, мәктәп исемнәре ничек кенә чәчәкле-чуклы булып, шул бизәкләргә татар сүзе дә кушылмасын, аларның чынлап та асыл татар мәктәбе икәненә ышанмыйм. Бу сүзләрне төрле мәктәпләргә очрашуга йөргән кеше буларак әйтәм. Бер яктан мондый фикерне әйтү, кызыклы чаралар оештырып, көч түгеп кунакка чакырган укытучылар алдында рәхмәтсезлек булыр. Ләкин анда укыткан милли җанлы мөгаллимнәр үзләре дә моны тоя! Тышкы яктан килешмәгән кыяфәт чыгарса да, күңел түрендә бу фикерне уртаклашадыр. Әйдәгез, татар мәктәпләренең кимчелекләрен санап үтик.

Беренчедән, ясалмалык. «Татар мәктәбе» кушаматлы мәгариф үзәкләрендә исеменнән гайре татар сүзе кулланылмый. Дөрес, чаралар татар телендә уза кебек. Анда кешеләр үзләрен гадәти тотмый, һаман татар сүзен кулланып, мәктәпләрен татарныкы дип исбатларга тырыша.

Икенчедән, рус мохите! Балалар бер-берсе белән бары тик урыс телендә генә аралаша. Татарча әйткәнне аңламыйлар. Минә без борчылып язган мәкаләләрне дә алар укымый. Аннары, татар мәктәбе булгач, анда тел «цензы» булырга тиештер бит! «Мин татартча блям!» – дигән балаларны да алалар икән. Нишлисең бит, укучы санын да тутырырга кирәк. Ата-аналары монда тәртип яхшы дип, баласын чит милләт мәктәбендә укыта. Очраклы гына рус мәктәпләре янынnan үткәндә ишеткән сүгенү сүзләреннән соң, андый ата-аналарның татар мәктәбенә бирүләрен яхшы аңлыйм!

Өченчедән, укыту теле дә урысча! Бусын инде шәһәр җирендә татар телле кадрлар җитмәү белән дә, ата-аналарның: «Балам югары уку йортында урыс телендәге фәнне аңламас!» – дигән ахмак фикере белән дә аңлатырга була. Сәер бит инде! Татар мәктәбе дигән исеме бар, югыйсә, ә гамәлдә чагылмый. Ана телендә кеше гыйлемне яхшырак үзләштерә, яхшырак сеңдерә икәнен галимнәр раслап тормаса да ачык аңлашыла. Мәктәптә татар телендә ун ел буе гел «биш»легә генә укыган укучы буларак әйтәм, әгәр бу фәннәрне русча өйрәнгән булсам, күбесеннән «өчле»ләрем чыгар иде. Ә университетта укыйсы чынлап та авыр, килешәм! Ул авырлыкка гына түзәргә мөмкин! Андый сынау шәхес буларак нығыта гына!

Бу мәсьәләнең тагын бер ягы бар: бала рус телендә генә сөйли ала торган шәхес итеп тәрбияләнә. Ул телевизордан түгел, берәр кечкенә генә чарада да ике җөмлә төзеп татарча әйтә алмый. Шөкер, рус телендә телевидениегә дә интервью биргәнем бар. Бер дә югалып калмадым, җөмләләрен төзеп чыктым. Татар кешесенә рус телендә камил сөйләшмәү гаеп түгел, ә туган телендә ике сүзне дә бергә ялгый алмау зур гөнаһ!

Моңа мисал итеп, татар классикларының балаларын да китерим әле. Исемнәрен атап тормыйм, үзегез дә чамаларсыз. Татар теленең иң нечкә үзенчәлекләрен тоеп язган, дөньякүләм билгеле бер шагыйребезнең баласы берәр очрашу-мазар булса, әтисе турында урысча сөйли. Икенче бер классигыбызның кызы да шулай ук русча сөйләде. Ләкин соңгысы үзенең ана телендә чыгыш ясый алмавы өчен татарча гафу үтенде. Моның сәбәбен рус мәктәбендә белем алуы белән аңлатты.

Казандагы, башка зур шәһәрләрдәге татар мәктәпләренең уңай яклары да бар. Суверенитет җилләре һичшиксез үз тәэсирен калдырды. Балалар да тәртипле, матур итеп исәнләшә дә белә. Укытучыларны да гаепләп булмый. Алай-болай шаулый башласалар, эшләреннән колак кагулары бар. Хәлләреннән килгән кадәр милләтебезгә хезмәт итәргә теләүчеләре күп!

Шулай да, болар гына аз! Бик аз! Мегаполисларда татар мохитен булдыру өчен нишләргә кирәктер белмим, әмма бер нәрсә ачык! Әгәр балаңның ана телендә матур итеп сөйләшә белүен теләсәгез, «Базар икътисады», «Хокук», «Табигать белеме», «Хезмәт» кебек дәресләр укытасыгыз килсә, һичшиксез, балагызны алдынгы саналган берәр татар авылы мәктәбенә бирегез! Ә Казанда Нельсон Вальдесны канәгатьләндергән испан мәктәбе генә түгел, ни кызганыч, үзен иң гади татар дип таныган, баласын чын мәгънәсендә татар зыялысы итеп үстерә торган мәктәп юк! Бу фикеремнең ялгыш икәнен белсәм, чын күңелемнән шатланыр идем.

• Белем баскычлары

# Мин үскәч галим булам

**Башы 1нче биттә.**

Тарих факультеты чыгарылыш студенты Дарья Корнилова бөтен җанын-тәнен биреп эшли: экскурсияләр оештыруда катнаша.

Балалар күңелсезләнеп утырырга ирек бирми. 39 номерлы мәктәпнең 4 сыйныф укучысы Антоний Свердруп: «Мин бөтен өлкәләр буенча да галим булачакмын», – диде. «Шифр һәм ни өчен хәрби донесениеләрне сер итеп тотканнар» дигән темага чыгыш ясады. Алай гына да түгел, ул өй эше дә бирде. Шәхси шифр уйлап табарга!

Балаларның әти-әниләре дә канәгать. Бер укучының әнисе Полина Макарова сүзләренә караганда, балалар лекцияләрдән бик сөенеп кайта. Алар әле үзләре өчен дә бик кызыклы мәгълүмат ала. Ә Фәридә Гыйльзетдинова киләсе лекцияләргә туган-тумачаларын чакырырга сүз бирде.

Мондый лекцияләр вакытында укучылар бик җитди. Яшьтән үк зур аудиториядә үзеңне ничек тотарга икәнлегең белеп үскәннәргә студент елларында җиңел булыр. Балачаклары компьютер артында үтеп киткән егет-кызлардан аермалы буларак, нәни студентлар үз максатларына тизрәк тә ирешер.

● Әдәби Ат

# Шомырт чәчәкләре

Нурсөя МИНЗИНА,
татар филологиясе бүлеге студенты

*(Хикәя)*

Гөлүсә ашыга-ашыга кибеткә узды. Кибеттә чират шактый. «Автобуска соңармасам ярар иде. Чәй генә алыйм. Алайса соң кайтыла, кибет бик иртә ябыла, җитешмәм», – дип уйлады ул.

– Апа, апа, мине тиз генә уздырып җибәрә алмассыз микән, бик ашыга идем, – каршындагы ханымга төртте.

– Сеңлем, мин дә бик ашыгам. Чиратыңны көтеп тор инде.

Ярты сәгать вакыт узып та китте. Гөлүсә автобуска җитешмәде, җәяү барырга булды. Көн эссе, җиле юк, машиналар тыз да быз йөреп тора, туктамыйлар. Үзе дә кул күтәрми. Шулай ике чакрым үтелде, аяклары бик арыды. Биек үкчәле туфлиен салып кулына тотты, юлын яланаяк дәвам итте. Асфальт юл бик кайнар, аякны пешерә иде. Кызуына түзә алмыйча, кире аягына киеп куйды кыз. Аягына көч-хәлгә баса-баса барды. Эшкә барганда Гөлүсә агачларны күзәтеп барырга ярата иде. Нинди төрле алар, бер-берсенә охшаганнары һич юк. Кечкенәсе-зурысы, зур яфраклысы, ылыслы наратлар да бар. Озак баргандырмы-юкмы, янына бер машина килеп туктады. Машина тулы егетләр, өенә кайтарырга сүз бирделәр. Гөлүсә, үз чиратында: «хәзер килеп алалар, сезнең белән кайтмыйм», - диде. Егетләр күпме генә үгетләсәләр дә, ризалашмады. Андый машиналарга, җитмәсә, егетләр янына утырырга шомлана ул. Егетләр дә үз юлларына китеп барды. Гөлүсәнең телефоны шалтырады.

– Әйе, тыңлыйм, әни.

– Сәлам, кызым. Син кайда әле?

– Юлда мин, бераздан кайтып җитәрмен. Берәр нәрсә булмагандыр бит?

– Юк, берни дә булмады, кызым, куркыттым, ахры. Карале, кызым, син хәтерлисеңме Дамир абыеңның армиядәге малаен?

– Түбән оч Дамир абыймы?

– Әйе, әйе, шул.

– Хәтерлим, Айзил бугай исеме. Яшьтәшем булырга тиеш. Күптән авылга кайтканы юк. Аның белән берни дә булмагандыр бит?

– Юк, юк, берни дә. Онытканмын да әйтергә, Дамир абыеңның улы, Айзил ялга авылга кайтты бүген. Аны очраткан идем дә, сине сорады. Эштән кайтырга тиеш дигән идем, сине алып төшәргә менеп китте. Хәзер юлда очрарга мөмкин.

– Ә, алай икән. Танысам ярый инде.

– Ярар, кызым, эшем бар иде. Сау бул.

– Хуш, әни!

Бераздан юлда Гөлүсәнең каршына бер машина килеп туктады. Тәрәзәне ачып, бер егет елмайды. Сөйкемле, чибәр, зурларча фикер йөртәдер кебек тоелды ул кызга.

– Сәлам, Гөлүсә! Әллә танымыйсың инде? Мин бит инде ул, синең балачак дустың.

– Сәлам, Айзил! Танадым, танымаслык булып үзгәргән булсаң да танадым.

– Әйдә, ишек аркылы сөйләшмик. Мин Дания апага сине җитез генә өеңә кайтарып куям дидем.

– Ярар, сүз биргәч утырам инде.

Бер-ике минут бер сүз әйтмичә бардылар, бары тик бер-берсенә елмаеп күз караштылар.

– Гөлүсә, сине хәзер танып та булмый, үзгәргәнсең.



– Танадың бит әле, килеп тә туктадың, хәзер өйгә кайтарып куям дидең. Син дә бик үзгәргәнсең.

– Әйе, бераз үзгәрдем. Мин сине күзләреңнән генә таныганмындыр. Алар һаман шундый матур, кара, гүя үзләренә әсир итә.

– Егет булгансың икән инде, кызларга «комплиментлар» да әйтәсең.

– Юк, мин әле дә биш ел элеккеге кебек малай гына. Синең арттан ябышкак келәй кебек йөргән малай...

– Алай димә. Егет булгансың бит. Җилкәләрең киң, тавышың калын, үз-үзеңне тотышың чын егетләрнеке! Бүген кайттың инде алайса. Ник бер тапкыр да биш ел эчендә кайтмадың? Мине дә оныткан булгансыңдыр инде.

– Юк, онытмадым, алай димә, күңелемдә син генә булачаксың. Әйе, шулай биш ел үтеп киткән икән. Армиягә бардым, тагын өч ел контракт белән калган идем, әзрәк олыгаеп кайтасым килде. Хәтерлисеңдер, мин синең яныңда бер елак малай гына идем. Үзем кечкенә буйлы, җебегән, бүтән егетләр янында яклый да алмый идем бит. Шуларны хәзер искә төшерәм дә, бераз уңайсыз булып китә.

– Уйлама ул турыда, Айзил. Барыбер, ни генә дисәк тә, күңелле чаклар иде ул. Эх, балачакны яңадан кайтарып булсамы...

– Әгәр дә андый мөмкинлек булса, нишләр идең?

– Юк, андый мөмкинлек бирелми.

– Юк, әйт инде, нишләр идең? Мин булыр идемме синең дустың?

– Әлбәттә. Әйдә хыялланып утырмыйк. Менә кайтып та җиттек. Абау, хәтта капка төбенә хәтле кайтарып куйдың. Рәхмәт, Айзил!

– Дәү үс, Гөлүсә. Гөлүсә, тукта, бераз гына көт. Сиңа бер соравым бар. Ә син бүген кич чыгасыңмы?

– Нигә алай дисең? Әллә мин кич чыксам, син дә чыгар идеңме?

– Әйе, әлбәттә. Әйдә бүген капка төбендә сөйләшеп утырабыз, балачакны искә төшерербез. Туктале, минем сиңа бер нәрсә бирәсем бар.

Айзил машинаның артын ачып, Гөлүсәгә шомырт чәчәкләре сузды.

– Хәтерлисеңме шомырт чәчәкләрен? – дип елмайды кыз.

– Хәтерлим, Гөлүсә, алар синең яраткан чәчәкләрең.

– Ярар. Айзил, мин керим инде. Рәхмәт барысы өчен дә. Кич белән очрашканга кадәр.

Кояш исә ике гашыйктан оялып, акрынлап офык артына кереп китәргә җыена иде.

## Каләм борлар

Равил ҺАДИ
Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты мөгаллиме

Аталган атаклы атны ата.
Бозлы бозлавыкта боз бозыла.
Борын-борыннан борчактан борчылып борындык борынын борган.
Буранда буран бура бурыйлар.
Казучы казнада казына.
Сазганнар сазы сазлыкта.
Сынык сынчы сынын сыный.
Уйлап уянган уят.
Ялангач ялачы ялагайланып ялый.

● Шигъри башваткыч

## Коңгыж-ж-ж

Ринат НУРУЛЛИН

*Җәй башында бер коңгыз,*
*Әй быжылдады көндез.*
*– Математик мин,– диде,–*
*Мин – коңгыз тапкыр ж-ж-жиде...*

*Аңламадым бер сүзен,*
*Ребус төзедем үзем,*
*Язып алырга житеш:*
*«КОҢГЫЗ х 7 = ЖЖЖЖЖЖ».*

*Шуннан соң кала гына*
*Хәрефләр урынына*
*Цифрларны куярга,*
*Ә коңгызны... куарга.*

***Алдагы санда чыккан ребусның ике чишелеше бар:***
*368 + 68 + 8 = 444;*
*582 + 82 + 2 = 666.*

**!** Башваткычка дөрес җавап бирүчеләр арасында Фәйрүзә Фатыйхова, Гөлнара Габдуллина, Алмаз Нурмөхәммәтов, Илмир Вәлиевлар бар иде. Ни кызганыч, ребусның бер генә чишелешен белгәнсез. Шуңа күрә иң беренче бер дөрес җавапны җибәргән Руфинә ГАБДРАХМАНОВАны җиңүче дип таптык. Аңа автор «Альпинист үрмәкүчләр»ен бүләк итә. Бүләкне редакциябездән килеп алырга мөмкин. Ә бу юлы җиңүче булмаганнар, борчылмагыз, башваткыч шигырьләр дә, китаплар да күп.

● Сәламәтлек

# Файдалы зыян

Алинә САДЫЙКОВА,
хәбәрче

Массажның ни икәнен дә белмәгән, аны яратмаган кеше бармы икән? Белгечләр аны төрле авырулардан профилактика һәм сәламәтлекне саклау өчен яхшы чара диләр. Әмма тискәре ягы да бар: бу күнелгә ятышлы процедура кешенең сәламәтлегенә шактый зур зыян да салырга мөмкин икән.

Һәркемгә билгеле, массаж күптөрле булырга мөмкин. Аның барлык төрләре ике дөньяви системага берләштерелгән: европалы һәм көнчыгыш. Европалы массаж дигәндә, Россия, Швеция һәм Финляндия илләренең танып белү һәм техникаларын куллану күздә тотыла, икенче төрле аны классик массаж дип тә атыйлар.

Әгәр массажның савыктыргыч тәэсирен үзегезнең сизәсегез килсә, тулы курс үтәргә тырышыгыз. Гадәттә, ул 10-15 сеанстан да ким булмый. Аны сәламәтлекнең дәрәҗәсенә карап, көн саен яисә көн аралаш алырга мөмкин. Шунысы мөһим: массажны бары тик бу өлкәдә белеме булган кеше – профессионал гына ясый ала. Начар әзерлекле кеше үзе дә белмичә сәламәтлеккә зур зыян салуы ихтимал. Моннан тыш, массаж бөтенләй ярамаган авырулар бар. Белер-белмәс дәвалану сәбәпле, кешенең гомере куркыныч астында калырга мөмкин.

Башыгызда «гади массаж нәрсәсе белән зыянлы була ала соң?» дигән сорау туарга мөмкин. Ни хикмәт, зарарлы була ала икән шул. Төрле күңелсезлекләргә тарымау өчен, иң элек табибка барып, аның белән сөйләшергә киңәш ителә. Ул сезне тикшергәннән соң, сәламәтлегегезгә файдалы массаж тәкъдим итә алачак.

Зарарлы авыруларга килгәндә, массажны организмында ялкынсыну процессы булган һәм югары температуралы кешеләргә ясарга ярамый. Чөнки массаж тәннең температурасын күтәрә һәм аның нәтиҗәсе нинди булуын алдан белү мөмкин түгел. Әгәр тәнегездә ялкынсыну процессы булса, массаж аны тагы да арттырып җибәрергә мөмкин. Моннан тыш, табибләр артык ябык кешеләргә тирән массаждан тыелырга киңәш итә, чөнки ул умыртка баганасы янындагы нервлар, мускул һәм сөякләргә зыян китерә ала.

Күп авыруларны дәвалаганда, классик массаж ысуллары белән беррәттән, көнчыгыш массажын да яратып кулланалар. Беренчесеннән аермалы буларак, ул тәндәге аерым нокталарга басып ясала. Фәнни медицинада аның исеме – акупрессура.

Акупрессураны бары тик бармак очлары белән генә ясыйлар. Көнчыгыш медицина белгечләре фикеренчә, нокталарга басу нәтиҗәсендә авыруны баса торган эндорфиннар барлыкка килә. Нәкъ шушы фактор табибларга баш, буыннар, гипертония, бронхиаль астма, ашказаны җәрәхәте авыруларыннан көнчыгыш практикасын кулланып дәваларга ярдәм итә.

Әлеге төр массаж планетабызның инде 30% кешеләре интегә торган, киң таралган гипертония авыруын дәвалауның бик нәтиҗәле һәм аяу төре булып тора.

Сүз дә юк, массажның файдасы зыянга карарганда күпкә зур. Шулай да, сәламәтлегегезне бары тик профессиональ массажчы куллары ярдәмендә генә төзәтү дөрес һәм нәтиҗәле булыр.



DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, Д.Р.Зиннәтова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.